ГЛАВА ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ
Чехов ур., 18 нче йорт, Югары ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39. E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

______________ с. Верхний Услон ______________

Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү турында Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы Министрлыгы боерыгы проекты буенча иҗтимагый фикер алышуларны билгеләү хакында

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы халкының яхшы тормыш шартларында яшәү хокукларын саклау, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары ияләренең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау максатында, Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексына, «Җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 20.03.2025 ел №33-ФЗ Федераль законына, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында иҗтимагый фикер алышуларны үткәрү турында Тәртипкә туры китереп, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитет мөрәҗәгатен карап,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы, Мәйдан авыл җирлеге, Мәйдан авылы, Совет урамы – «элемтә» 16:15:100101:1175 кадастр номеры белән, 749 кв. м. мәйданы булган, ИЖ1 (индивидуаль корылыш зонасы) җир куллану һәм кору кагыйдәләре зонасында урнашкан җир участогына шартлы рөхсәт ителгән куллану рөхсәте бирү турында Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы Министрлыгы боерыгы проекты буенча иҗтимагый фикер алышуларны үткәрүне билгеләргә.

2. Бүгенге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән проектны карау буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы итеп Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеген (алга таба – җәмәгать фикер алышуларын оештыручысы) билгеләргә.

3. Җәмәгать фикер алышуларын оештыручы - коллегиаль киңәшмә орган составын расларга:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе А.А. Әхмәтшин;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге начальнигы А.Д. Сагдиева;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советының оештыру-хокукый һәм кадр эше бүлеге начальнигы Н.В. Пичугина;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге башлыгы вазифаларын вакытлыча башкаручы З.Н. Файзрахманова.

4. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручысына иҗтимагый фикер алышуларны эшлекле законнарга туры китереп оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итүне йөкләргә.

5. Иҗтимагый фикер алышуларны үткәрү чорын 2026 елның 17 августыннан 2026 елның 5 сентябренә кадәр билгеләргә.

6. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручысына иҗтимагый фикер алышулар башлану турында хәбәрне Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясына туры китереп әзерләүне йөкләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында (https://verhniy-uslon.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы Е.А. Варакин